КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 декабрь г.Казань № 1140

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәскәү – Казан» югары тизлектәге тимер юл магистрален төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервка кую турында» 2016 ел, 21 июнь, 416 нчы карары нигезендә билгеләнгән җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир хуҗаларының, аларны арендага алучыларның хокукларын чикләүләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан исәптән төшерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының $70^1$ статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә югары тизлекле тимер юл транспорты хәрәкәтен оештыру чаралары турында» 2010 елның 16 мартындагы 321 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервка куюга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең Транспорт стратегиясе турында» 2008 елның 22 ноябрендәге б-1734 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль транспорт (тимер юл, һава, диңгез, эчке су транспорты) һәм федераль әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2013 елның 19 мартындагы б-384 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир хуҗаларының, аларны арендага алучыларның торак, җитештерү, мәдәни-көнкүреш

һәм башка биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәскәү – Казан» югары тизлектәге тимер юл магистрален төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервка кую турында» 2016 ел, 21 июнь, 416 нчы карары нигезендә билгеләнгән хокукларын чикләүләрне, дәүләт ихтыяҗлары өчен аларны резервка кую вакыты чыгуга бәйле рәвештә, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан исәптән төшерү турындагы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен документларны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә билгеләнгән тәртиптә кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәскәү – Казан» югары тизлектәге тимер юл магистрален төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервка кую турында» 2016 ел, 21 июнь, 416 нчы карары, резервка кую вакыты чыгуга бәйле рәвештә, үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

5. Бу карар резервка куела торган җир кишәрлекләренең урнашу урыны буенча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш һәм басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин